| | |
|---|---|
| СОВЕТ ШЕЛАНГОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ ШИЛАНГЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

27.10.2022 с. Шеланга 22-113

Югары Ослан муниципаль районының Шилангы авыл җирлеге Шилангы авылы торак пункты территориясендә гражданнарның үзара салымын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Шилангы авыл җирлеге Уставы нигезендә, Шилангы торак пунктының бер өлешендә яшәүчеләр төркеме инициативасын карап чыгып,

Югары Ослан муниципаль районының
Шилангы авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. 2022 елның 8 октябрендә Югары Ослан муниципаль районының Шилангы авыл җирлеге Шилангы авылы территориясендә гражданнардан үзара салым акчасын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«2023 елда Югары Ослан муниципаль районының Шилангы авыл җирлеге Шилангы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 4100 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме:

- Шилангы авылының Заводская урамы буенча юлны реконструкцияләү

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Гражданнар җыенын түбәндәге адрес буенча уздырырга: Шилангы авылы, Завод урамы, 7 нче йорт янында 10.00 сәгатьтә.

4. Гражданнар җыенын оештыручы итеп Шиланга авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

5. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында, шулай ук җирлекнең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Совет рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Шилангы авыл җирлеге башлыгы В. В. Майоров